Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл жирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

13.11. 2020 ел №18

«Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегенең Югары Өскебаш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегенең Югары Өскебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар жыенын Югары Өскебаш авылы, Сабир Ахтямов урамы, 38А нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә хәтле 4 һәм аннан артык бала булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегенең Югары Өскебаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны Югарыдәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Югары Өскебаш авылы Сабир Ахтямов урамына вак таш жәеп ремонт ясау; проект-смета документларын төзү , технадзор;

- Югары Өскебаш авылында юлларны кыш коне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;

- видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Югары Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар жыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Түбән Өскебаш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов